КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 29 март г.Казань № 192

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында мәктәп автобусларын нәтиҗәле файдалану чаралары турында» 2006 ел, 3 август, 400 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы белем алучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру хакындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында мәктәп автобусларын нәтиҗәле файдалану чаралары турында» 2006 ел, 3 август, 400 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 29 ноябрь, 669 нчы; 2016 ел, 30 декабрь, 1070 нче; 2018 ел, 23 гыйнвар, 29 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы белем алучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

6 нчы пунктның тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«D» категориядәге транспорт чарасын йөртүче сыйфатында өзлексез эш стажы балалар төркемнәрен оештырылган рәвештә йөртә башлаган көнгә кимендә бер ел булган;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин